РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.06.2016 г.Бугульма № 732

**Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 гыйнварында кабул ителгән №7 карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210 номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында:

1. Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2016 елның 11 гыйнварындагы №7 карарына кушымтада үзгәреш кертергә.
2. 5.1 пунктының 5 өлешендә объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге эчтәлекле 2 абзац өстәргә:
   Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның вазыйфаи затлары, яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләргә карата юридик затларга һәм шәһәр төзелеше мөнәсәбәтләре субъектлары булып торучы индивидуаль эшкуарларга карата процедураларның тулы исемлегенә кертелгән процедураларның карарларына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Россия Федерациясенең Монополиягә каршы законнары белән билгеләнгән тәртиптә монополиягә каршы органга мондый затлар тарафыннан тапшырылырга мөмкин.
3. Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр бүлегенә әлеге карар кабул ителгәннән соң, 3 эш көне эчендә аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә –

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр бүлегенә әлеге карар кабул ителгәннән соң, биш эш көне эчендә объектны яңа редакциядә файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын урнаштыруны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына йөклим.

Җитәкче А.Р. Галиуллин